СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
2015 елның 10 ноябре

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
№ 22

2015 елның тугыз аенда Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту турында

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дѐгтеваның 2015 елның тугыз аенда Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту турында мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы карар **карар кылды**:

1. 2015 елның тугыз аенда Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту турындагы мәгълүматны игътибарга алырга (кушымтада бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

| | | |
|---|---|---|
| ***01.10.2015 ел торышына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларның тотылуы турында белешмәләр*** | | |
| | | |
| ***№ т/б*** | ***Түләү максаты*** | ***Сумма (сум)*** |
| 1 | Янгыннан зыян күрүчеләргә матди ярдәм күрсәтү | 238 600,00 |
| 2 | Дәвалануга матди ярдәм күрсәтү | 529 000,00 |
| 3 | Үлем белән бәйле рәвештә матди ярдәм күрсәтү" | 20 000,00 |
| 4 | Матди ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 781 026,10 |
| 5 | «Бөтендөнья оешмасының Евразия региональ бүлеге Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр» халыкара ассоциациясенең 2014 елгы еллык әгъза взносын түләү | 72 000,00 |
| 6 | 2015 ел өчен «Бөтендөнья оешмасының Евразия региональ бүлеге Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр» халыкара ассоциациясе еллык әгъза взносын түләү | 93 935,00 |
| 7 | “Созвездие - Йолдызлык - 2015” XV ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестиваленең зона финалында призлы урыннар алган мәдәният, спорт һәм мәгариф учреждениеләре иҗат коллективлары җитәкчеләренә һәм педагогларына матди түләүләр | 158 500,00 |
| 8 | "ТР Зеленодольск муниципаль районының мактаулы гражданины", "ТР ЗМР алдындагы казанышлары өчен" | 263 000,00 |
| 9 | Мәктәп формасын алу өчен матди ярдәм күрсәтү | 23 000,00 |
| 10 | Украина территориясеннән китәргә мәҗбүр булган һәм Зеленодольск муниципаль районы территориясенә килгән Украина гр. матди ярдәм күрсәтү | 5 743,00 |
| 11 | Тамбов шәһәрендә спортчының һәм тренерның терәк хәрәкәт аппараты зарарланган затлар арасында пауэрлифтинг буенча Россия беренчелегенә сәяхәтен оештыру өчен Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасының Зеленодольск шәһәр һәм район оешмасына матди ярдәм күрсәтү | 36 240,00 |
| 12 | Резерв фонды күләме киму РИК ның 2015 елның 09 сентябрендәге 699 номерлы күрсәтмәсе нигезендә (РИК 16.10.2015 № 835 күрсәтмәсе нигезендә Резерв фонды күләме торгызылды) | 305 747,89 |
| 13 | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә йогышлы авырулар учакларында эпидемиягә каршы чаралар үткәрү өчен. | 125 697,00 |